ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

30.11.2022 Олы Кайбыч ав. № 519

Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының «Өлешчә мобилизация кысаларында хәрби хезмәткә чакырылган гражданнарның балаларын мәктәпкәчә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы Кайбыч муниципаль районы мәгариф оешмаларында тәрбияләнгән өчен түләүдән азат итү турында» 2022 елның 06 октябрендәге 447 номерлы карарына үзгәрешәр кертү хакында

Министрлар Кабинетының «Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган Россия Федерациясе гражданнарының гаиләләренә ярдәм итүнең өстәмә чаралары турында» Татарстан Республикасы 2022 елның 20 октябрендәге 1122 номерлы карары, «Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган Россия Федерациясе гражданнарының гаиләләренә ярдәм итүнең өстәмә чаралары турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 елның 20 октябрендәге 1122 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2022 елның 14 ноябрендәге 1213 номерлы карары нигезендә Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР ИТТЕ:

1. Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының «Өлешчә мобилизация кысаларында хәрби хезмәткә чакырылган гражданнарның балаларын мәктәпкәчә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы Кайбыч муниципаль районы мәгариф оешмаларында тәрбияләнгән өчен түләүдән азат итү турында» 2022 елның 06 октябрендәге 447 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Өлешчә мобилизация кысаларында хәрби хезмәткә чакырылган, махсус хәрби операциядә катнашу нәтиҗәсендә һәлак булучылар (вафат булучылар) гражданнарның балаларын мәктәпкәчә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы Кайбыч муниципаль районы мәгариф оешмаларында тәрбияләнгән өчен түләүдән азат итү турында»;

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган махсус хәрби операциядә катнашучы гражданнарның, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә, Россия Федерациясе милли гвардиясендә хезмәт итүче хәрби хезмәткәрләр һәм затлар, Татарстан Республикасында төзелгән «Алга» һәм «Тимер» батальоннарында хәрби хезмәт узучы гражданнар, махсус хәрби операция барышында хәрби бурычларны ирекле үтәүче гражданнар, Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы, Россия Федерациясе Федераль куркынычсызлык хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе хезмәткәрләренә махсус хәрби операция уздыру зонасына командировкага кертелгән гражданнар, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашу нәтиҗәсендә һәлак булган (вафат булган) гражданнарның балаларын Кайбыч муниципаль районының мәктәпкәчә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларында балаларны тәрбияләгән өчен алына торган түләүдән азат итәргә.»

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге http:/ kaybici.tatarstan.ru веб-адресы буенча рәсми сайтында урнаштырырга һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны «Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге» МКУ башлыгы И.И. Хәмидуллинга йөкләргә.

Җитәкче А.Н.Макаров